**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 14 маендагы 1449 номерлы карары**

**Кадастр номеры 16:16:120602:13089 булган җир кишәрлеге чикләрендә территорияне ызанлау проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе гаризасы буенча, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43, 45, 46 статьялары, 2023 елның 10 июлендәге 305-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдән чыгуын тану хакында»гы федераль законның 8 статьясы, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 10 мартындагы 640 номерлы «Кадастр номеры 16:16:120602:13089 булган җир кишәрлеге чикләрендә территорияне ызанлау проектын әзерләү турында»гы карары, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2016 елның 29 декабрендәге 5410 номерлы карары белән расланган Мамадыш Тракты урамы буенча территорияне планлаштыру проекты нигезендә карар бирәм:

1. 16:16:120602:13089 кадастр номеры булган җир кишәрлеге чикләрендә территорияне ызанлау проектын әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә (А.П.Горбунов):

2.1. әлеге карарга кушымта нигезендә җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куюю өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә;

2.2. җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә куйганнан соң, адреслы номер бирү һәм белешмәләрне Дәүләт адреслар реестрына кертү өчен Казан

шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсенә җир кишәрлекләренең кадастр номерлары турында мәгълүмат бирергә;

2.3. җир кишәрлекләреннән алга таба файдаланганда:

2.3.1. инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренең куркынычсызлыгын һәм әлеге челтәрләрне эксплуатацияләүче оешмалар өчен аларга тоткарлыксыз керүне тәэмин итәргә;

2.3.2. территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә.

3. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны, ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (кушымта) (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2025 елның
14 маендагы 1449 номерлы
карары белән расланды

**Кадастр номеры 16:16:120602:13089 булган җир кишәрлеге чикләрендә территорияне ызанлау проекты**

Кадастр номеры 16:16:120602:13089 булган җир кишәрлеге чикләрендә территорияне ызанлау проекты түбәндәгеләрдән тора:

I. Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә.

II. Территорияне ызанлау проектын сызымы.

Ызанлау проекты территориясе чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге, ясала торган җир кишәрлекләре чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып санала һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (ww.docskzn.ru) бастырып чыгарылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

## I. Территорияне ызанлау проекты турында нигезләмә

Территорияне ызанлау проекты, Россия Федерациясе Җир кодексының 11.2 статьясындагы 3 пункты нигезендә, беренчел җир кишәрлеген муниципаль милектәге үзгәртелгән чикләрендә саклап калып, башлангыч җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре – «гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләрен (территорияләрен)» билгеләп, 16:16:120602:13089 кадастр номерлы җир кишәрлеген бүлү юлы белән шартлы номерлары: ЗУ1 һәм :ЗУ2 булган җир кишәрлекләре ясалуны күздә тота

Ясала торган җир кишәрлекләренә карата Россия Федерациясе Җир кодексының 11.9 статьясы белән билгеләнгән таләпләр үтәлгән.

Шартлы номерлары :ЗУ1 һәм :ЗУ2 булган ясала торган җир кишәрлекләре

турында белешмәләр таблицада китерелгән.

Кадастр эшләрен башкарганнан соң, шартлы номерлары :ЗУ1 һәм :ЗУ2 булган ясала торган җир кишәрлекләренә, җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләрен таблица нигезендә билгеләргә тәкъдим ителә.

Таблица

| **Җир кишәрлегенең шартлы номеры** | **Ясала торган җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төре** | **Беренчел җир кишәрлегенең кадастр номеры** | **Җир кишәрлегенең мәйданы, кв.м** |
|---|---|---|---|
| :ЗУ1 | Территорияне төзекләндерү | 16:16:120602:13089 | 14201 |
| :ЗУ2 | Территорияне төзекләндерү, коммуналь хезмәтләр күрсәтү | 16:16:120602:13089 | 3671 |

Әлеге ызанлау проекты белән ясала торган җир кишәрлекләре график өлештә күрсәтелгән.

Шартлы номерлары :ЗУ1 һәм :ЗУ2 булган ясала торган җир кишәрлекләре Р2 рекреация билгеләнешендәге территориаль зонада урнашкан.


Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең «Барлык территориаль зоналар өчен гомуми шәһәр төзелеше регламенты» дигән 26 статьясы нигезендә җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре – «территорияне төзекләндерү» һәм «коммуналь хезмәтләр күрсәтү» төрләрен рекреация зонасында максималь һәм минималь чик үлчәмнәре билгеләнмәгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре буларак билгеләргә мөмкин (Р2).

Формалаштырылган җир кишәрлекләре түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

– - ихтыяҗ булганда һәм яңа инженерлык коммуникацияләрен салу өчен башка трассаны сайлау мөмкинлеге булмаганда, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, тоткарлыксыз керү мөмкинлеген;

– - гамәлдәге инженерлык коммуникацияләрен ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү өчен, җир кишәрлеге хуҗасы белән килештереп, эксплуатацияләүче оешмаларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген.

# II. Территорияне ызанлау сызымы




**Масштаб 1:2 200**

## Шартлы билгеләр:

- территорияне ызанлау проекты расланган территория чикләре;

- гамәлдәге (саклана торган) җир кишәрлегенең чикләре;

- кадастр кварталы чикләре;

:ЗУ1 - ясала торган җир кишәрлегенең шартлы номеры;

16:16:120602 - кадастр кварталы номеры;

1 ясала торган җир кишәрлеге чикләренең характерлы ноктасы номеры

ясала торган җир кишәрлеге чикләре

- гамәлдәге җир кишәрлегенең чикләре;

красная линия - урам-юл челтәренең гамәлдәге кызыл линиясе;

:13089 - җир кишәрлегенең кадастр номеры;

1 - территорияне ызанлау проекты чикләренең характерлы ноктасы номеры